СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.04.2026 г. Заинск № 43

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

2016 елның 15 ноябрендәге 174 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврино авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләрне раслау турында»;

2021 елның 25 августындагы 118 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»;

2021 елның 25 августындагы 140 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карарлары.

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (https://zainsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Советының экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, ТКХ һәм транспорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**